СОВЕТ
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2020 с. Мокрые Курнали № 128

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм остәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы карары хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 нче маддәсе, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 нче маддәсе нигезендә

**Бутлеровка авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы карары проектын (кушымта) хупларга.
2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге советы карарына һәм гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

3.1. Гавами тыңлаулар уздыру датасы - 10. 03.2020.

3.2.Гавами тынлаулар уздыру вакыты - 13.00 сәгать

3.3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасын гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Юеш Көрнәле авылы, Мәктәп урамы, 12 йорт адресы буенча билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетына күрсәтелгән карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетына, гавами тынлауларда әйтелгән һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге советы сессиясен карауга кертергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

8. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 нче маддәсендәге 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **Ф.А. Хәйретдинова**

СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Бутлеровка авыл җирлеге Советының
28.02.2020 елның
128 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск мунчципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **30 нчы маддәдә:**

**а)** 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 10 депутаттан тора».

**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **Ф.А. Хәйретдинова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Бутлеровка авыл җирлеге Советының
28.02.2020 елның
128 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУТЛЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАР ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ ГРАЖДАННАРНЫҢ АНЫҢ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУЛАРДА КАТНАШУЫ ТӘРТИБЕ**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Юеш Көрнәле авылы, Мәктәп урамы, 12 йорт, язма рәвештә.

Тәкъдимнәр «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты тексты урнаштырылган көннән алып 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителә.

2. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Юеш Көрнәле авылы, Мәктәп урамы, 12 йорт, шәхсән яисә почта аша («Устав турында фикер алышу» конвертында тамга белән).

**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **Ф.А. Хәйретдинова**

СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ